| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2024 г.Казань № 739-266/тп-2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2025 елга мөрәҗәгать итүчеләрнең энергия кабул итү җайланмаларын һәм (яисә) микрогенерация объектларын челтәр оешмаларының Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан электр челтәрләренә технологик тоташтырганда сорала торган максималь куәтнең кВт өчен ташламалы ставкаларны билгеләү турында» 20.11.2024 ел, № 340-257/тп-2024 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 4 декабрендәге 1709 номерлы карарын кабул итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 27.12.2024 ел, №38-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2025 елга мөрәҗәгать итүчеләрнең энергия кабул итү җайланмаларын һәм (яисә) микрогенерация объектларын челтәр оешмаларының Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан электр челтәрләренә технологик тоташтырганда сорала торган максималь куәтнең кВт өчен ташламалы ставкаларны билгеләү турында» 20.11.2024 ел, № 340-257/тп-2024 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Көнкүреш һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен файдаланыла һәм электр белән тәэмин итү бер чыганак буенча карала торган, максималь егәрлеге 15 кВт артмаган (әлеге тоташтыру ноктасына элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү җайланмаларын исәпкә алып) һәм ышанычлылыгы буенча өченче категориягә кертелгән (электр энергиясе белән тәэмин итүнең берәр чыганагы буенча), көчәнеш дәрәҗәсе 0,4 кВ һәм аннан түбәнрәк булган челтәр оешмасының электр челтәрләре хуҗалыгы объектларына тоташтырыла торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру

максатларында гариза биргән мөрәҗәгать итүче – физик зат өчен, мөрәҗәгать итүче кишәрлеге чикләреннән мөрәҗәгать итүче өчен кирәкле булган, үзенә карата гариза бирелгән челтәр оешмасының көчәнеш классына кадәр иң якын электр челтәре объектына кадәрге аралык шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метрдан артмаган һәм авыл җирлегендә 500 метрдан артмаган шарт белән, сорала торган максималь егәрлекнең һәр кВт өчен (өстәмә хак салымын исәпкә алып) 6 600 сум күләмендә ташламалы ставка билгеләргә.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Көнкүреш һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен файдаланыла һәм электр белән тәэмин итү бер чыганак буенча карала торган, максималь егәрлеге 15 кВт артмаган (әлеге тоташтыру ноктасына элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү җайланмаларын исәпкә алып) һәм ышанычлылыгы буенча өченче категориягә кертелгән (электр энергиясе белән тәэмин итүнең берәр чыганагы буенча), көчәнеш дәрәҗәсе 0,4 кВ һәм аннан түбәнрәк булган челтәр оешмасының электр челтәрләре хуҗалыгы объектларына тоташтырыла торган микрогенерация объектларын, шул исәптән бер үк вакытта энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру максатларында гариза биргән мөрәҗәгать итүче – физик затлар өчен, мөрәҗәгать итүче кишәрлеге чикләреннән мөрәҗәгать итүче өчен кирәкле булган, үзенә карата гариза бирелгән челтәр оешмасының көчәнеш классына кадәр иң якын электр челтәре объектына кадәрге аралык шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метрдан артмаган һәм авыл җирлегендә 500 метрдан артмаган шарт белән, сорала торган максималь егәрлекнең һәр кВт өчен (өстәмә хак салымын исәпкә алып) 6 600 сум күләмендә ташламалы ставка билгеләргә.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хәбибуллина